**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№01**
**09.01.2023**

Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү өчен комиссия төзү, критерийларны, шулай ук эксперт бәяләве формаларын раслау турында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 2 һәм 4 пунктлары, Татарстан Республикасының «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ Законының 13 статьясының 5 өлеше, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ Законының 3 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) төзергә.

2. Расларга:

1) Комиссия составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) муниципаль оешма тарафыннан муниципаль оешмагага беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяли торган критерийларны, 2 нче кушымтада каралганча;

3) муниципаль оешма тарафыннан муниципаль оешмагага беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча эксперт бәяләве формаларын, 3-5 нче кушымталарда каралганча.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү һәм муниципаль белем бирү оешмасына оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендалау яки аннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү нәтиҗәләрен бәяләү буенча даими эшләүче комиссия төзү турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 312 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия составы

1. Комиссия рәисе – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары.
2. Комиссия рәисе урынбасары – тармак идарәсе башлыгы.
3. Комиссия секретаре – муниципаль оешма җитәкчесе урынбасары/белгеч/өлкән тәрбияче.
Комиссия әгъзалары:
4. Тармак идарәсе башлыгы урынбасары /тармак идарәсе белгече.
5. Муниципаль оешма җитәкчесе.
6. Җәмәгатьчелек вәкилләре, 2 кеше (килешү буенча).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмалар тарафыннан аларга беркетелгән милек объектларына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча критерийлар

| Критерийлар | Үтәлеше |
|---|---|
| Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында, тиешле карар кабул ителгәнчегә кадәр, арендага, түләүсез файдалануга бирергә тәкъдим ителә торган социаль инфраструктура объектыннан файдаланып күрсәтелә торган мондый хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә балаларга хезмәтләр күрсәтү | Әйе/юк |
| Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында, балаларга аны арендага, түләүсез файдалануга бирергә тәкъдим ителә торган социаль инфраструктура объектыннан файдаланып күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүне дәвам итү | Әйе/юк |
| Социаль инфраструктура объектыннан файдалану турында карарны үтәү нәтиҗәсендә балалар өчен социаль инфраструктура объектының норматив таләпләргә туры килүен тәэмин итү | Әйе/юк |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
3 нче кушымта

форма

Мөлкәтне арендалау шартнамәсе төзү нәтиҗәләрен
ЭКСПЕРТ БӘЯЛӘВЕ

«____»_________202_ _ел

Түбәндәге составтагы эксперт комиссиясе:

Комиссия рәисе: ___________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия рәисе урынбасары: _____________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия секретаре: _______________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия әгъзалары: _______________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и)

_______________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 пункты нигезендә, балаларга белем бирү, аларны үстерү, тәрбияләү, социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен ____________________________________________________________оператив идарәсендә булган мөлкәтне арендага бирү нәтиҗәләрен бәяләү турында әлеге бәяләмәне төзеде.

Объект: _______________________________________________________________
(биналар, корылмалар, бүлмәләр: уку, уку-җитештерү,
торак булмаган һ.б. биналар, күчемсез милек объектының статусын төгәл күрсәтеп)

Объектның адресы:
_______________________________________________________________________

Балансta тотучы: _______________________________________________________
(учреждение исеме)

Гариза бирүче:
_______________________________________________________________________
(юридик затның исеме яки физик затның Ф.И.А.и.)

Мөлкәтне арендалау максаты: ________________________________________________

Мөлкәтне арендалау шартнамәсенең срогы: _____________________________________

Объекттан файдалану вакыты: _______________________________________________

Бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия билгеләде:

1. Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында, тиешле карар кабул ителгәнчегә кадәр, бер өлешен арендага бирергә тәкъдим ителә торган бинадан файдаланып күрсәтелә торган мондый хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә балаларга хезмәтләр күрсәтү: тәэмин ителәчәк/ тәэмин ителмәячәк
(кирәклесенең астына сызарга)

2. Объекттан файдалану турында карарны үтәү нәтиҗәсендә объектның норматив таләпләргә туры килүе: тәэмин ителәчәк/тәэмин ителмәячәк

(кирәклесенең астына сызарга)

Нәтиҗә: объект мөлкәтен арендага бирү: мөмкин/мөмкин түгел

(кирәклесенең астына сызарга)

Комиссия рәисе: ____________________________________________(______________________)
Комиссиия рәисе урынбасары __________________________________(______________________)
Комиссия секретаре: _________________________________________(______________________)

Комиссия әгъзалары: ________________________________________(______________________)
________________________________________(______________________)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
4 нче кушымта

форма

Мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү нәтиҗәләрен
ЭКСПЕРТ БӘЯЛӘВЕ

«____»_______202___ел

Түбәндәге составтагы эксперт комиссиясе:

Комиссия рәисе: ________________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия рәисе урынбасары: ______________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия секретаре: ____________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия әгъзалары: ____________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и)

____________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 пункты нигезендә, балаларга белем бирү, аларны үстерү, тәрбияләү, социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен____________________________________________оператив идарәсендә булган мөлкәтне түләүсез файдалануга бирү нәтиҗәләрен бәяләү турында әлеге бәяләмәне төзеде.

Объект: ________________________________________________________________
(биналар, корылмалар, бүлмәләр: уку, уку-җитештерү,
торак булмаган һ.б. биналар, күчемсез милек объектының статусын төгәл күрсәтеп)

Объектның адресы: ________________________________________________________

Баланста тотучы: __________________________________________________________
(учреждение исеме)

Гариза бирүче: ___________________________________________________________
(юридик затның исеме яки физик затның Ф.И.А.и.)

Максат ________________________________________________________________

Аренда шартнамәсенең срогы: ______________________________________________

Объекттан файдалану вакыты: ______________________________________________

Бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия билгеләде:

1. Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында, тиешле карар кабул ителгәнчегә кадәр, бер өлешен арендага бирергә тәкъдим ителә торган бинадан файдаланып күрсәтелә торган мондый хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә балаларга хезмәтләр күрсәтү: тәэмин ителәчәк/тәэмин ителмәячәк
(кирәклесенең астына сызарга)

2. Объекттан файдалану турында карарны үтәү нәтиҗәсендә объектның норматив таләпләргә туры килүе: тәэмин ителәчәк/тәэмин ителмәячәк
(кирәклесенең астына сызарга)

Нәтиҗә: мөлкәтне түләүсез файдалануга бирү: мөмкин/мөмкин түгел
(кирәклесенең астына сызарга)

Комиссия рәисе: ______________________________________________(_______________________)
Комиссиия рәисе урынбасары __________________________________(________________________)
Комиссия секретаре: ___________________________________________(________________________)

Комиссия әгъзалары: __________________________________________(________________________)
___________________________________________(________________________)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
5 нче кушымта

форма
Мөлкәтне арендалау шартнамәсен пролонгацияләү нәтиҗәләрен
ЭКСПЕРТ БӘЯЛӘВЕ

«____»_________202_ел

Түбәндәге составтагы эксперт комиссиясе:

Комиссия рәисе: ____________________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)
Комиссия рәисе урынбасары: _________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)
Комиссия секретаре: ________________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

Комиссия әгъзалары: ________________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и)
________________________________________________________________
(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 4 пункты нигезендә, балаларга белем бирү, аларны үстерү, тәрбияләү, социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен____________________________________________________________оператив идарәсендә булган мөлкәтне арендага бирү нәтиҗәләрен бәяләү турында әлеге бәяләмәне төзеде.

Аренда объекты: ____________________________________________________________________
(биналар, корылмалар, бүлмәләр: уку, уку-җитештерү,
торак булмаган һ.б. биналар, күчемсез милек объектының статусын төгәл күрсәтеп)
Объектның адресы:
____________________________________________________________________________________

Балансча тотучы: ____________________________________________________________________
(учреждение исеме)
Гариза бирүче: ______________________________________________________________________
(юридик затның исеме яки физик затның Ф.И.А.и.)
Мөлкәтне арендалауның максаты _______________________________________________________

Мөлкәтне арендалау шартнамәсен пролонгацияләү срогы: ________________________________

Объекттан файдалану вакыты: _________________________________________________________

Бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия билгеләде:

1. Балаларның тормыш эшчәнлеген, белемен, үсешен, ялын һәм аларны сәламәтләндерүне тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатларында, балаларга бер өлешен арендага бирергә тәкъдим ителә торган бинадан файдаланып күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күрсәтүне дәвам итү: тәэмин ителәчәк/тәэмин ителмәячәк
(кирәклесенең астына сызарга)

2. Объекттан файдалану турында карарны үтәү нәтиҗәсендә объектның норматив таләпләргә туры килүе: тәэмин ителәчәк/тәэмин ителмәячәк
(кирәклесенең астына сызарга)

Нәтиҗә: объектны арендага бирүне пролонгацияләү: мөмкин/мөмкин түгел
(кирәклесенең астына сызарга)

Комиссия рәисе: ___________ ___________________________________(________________________)
Комиссиия рәисе урынбасары ___________________________________(________________________)
Комиссия секретаре: _____________________________________________(________________________)

Комиссия әгъзалары: _____________________________________________(________________________)
_____________________________________________(________________________)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева